Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Үзбәк торак пунктында гражданнар җыены

КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай авыл җирлегенең Үзбәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлеге Үзбәк торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай авыл җирлеге Үзбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, буенча теркәлгән, балачактан инвалидлар, шулай ук 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы хәрби хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннары, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзалары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мең) сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кар чистарту

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зәй - Каратай авылы, Совет урамы, 99 йорт, 1 корылма, Үзбәк авылы, Луговая урамы, 2 йорт буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы М.И.Идиятова